**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе турында» 2004 елның 27 мартындагы ПУ-290 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2007 елның 16 мартындагы ПУ-126 номерлы, 2012 елның 4 июнендәге ПУ-416 номерлы, 2016 елның 12 декабрендәге ПУ-1091 номерлы, 2020 елның 16 апрелендәге ПУ-231 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 3 июлендәге 461 номерлы, 2024 елның 11 июнендәге 439 номерлы һәм 2024 елның 14 октябрендәге 798 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан А.И. Поминовны чыгарырга;

б) Комиссия составына Мөҗипов Рәмис Габдерәис улын – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты җитәкчесен кертергә;

в) Комиссия әгъзасы С.М. Захарованың вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2025 ел, 27 октябрь
№ 877